Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районы Олы Карамалы авыл җирлеге Советы карары

30.05.2017ел. № 42

Муниципаль районның җирле әһәмияттәге аерым мәсьәләләрне хәл итү буенча вәкаләтләрне тапшыру турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 15 статьясындагы 4 өлеше нигезендә Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районы Олы Карамалы авыл җирлеге Советы КАРАР ИТТЕ:

1. Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районы Советына җирле әһәмияттәге түбәндәге мәсьәләләрне хәл итү буенча авыл җирлеге башкарма комитетына Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районы башкарма комитеты вәкаләтләрен тапшыру турындагы мәсьәләне карарга тәкъдим итәргә:

җирлекнең генераль планнарын, җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләрен раслау, җирлекнең генераль планнары нигезендә әзерләнгән территорияне планлаштыру буенча документларны раслау, җирлекләрне шәһәр төзелеше проектларының җирле нормативларын раслау.

2. Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районы Советы әлеге карарның 1 пунктында күрсәтелгән тәкъдимне кабул иткән очракта, Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районы Олы Карамалы авыл җирлеге башкарма комитетына Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районы Башкарма комитеты белән әлеге карарның 1 пунктында күрсәтелгән вәкаләтләрне тапшыру турында килешү төзергә.

3. Әлеге карарны мәгълүмат стендларында игълан итәргә:

ТР, Кама Тамагы районы, Олы Кармалы авылы, Үзәк ур., 4;

ТР, Кама Тамагы районы, Баргуҗа авылы, Тукай ур., 16.

шулай ук Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районының рәсми сайтында Олы Карамалы авыл җирлеге бүлегендә урнаштыру юлы белән дә.

4. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районының Олы Карамалы авыл җирлеге башлыгы итеп йөкләргә.

Кама Тамагы муниципаль районы
Олы Карамалы авыл җирлеге башлыгы,
Кама Тамагы муниципаль районы
Олы Карамалы авыл җирлеге Советы рәисе Э.И.Байдамшин